Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге
Урта Дәүләзәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

3 ноябрь, 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең Урта Дәүләзәр торак пунктында 2025 елның 3 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 30 (утыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 20 (егенрме).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 20 (егерме).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2026 елда Урта Дәүләзәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- Урта Дәүләзәр торак пункты чикләрендә (Ленин ур., Луговая ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Екатериновка авыл җирлеге башлыгы П.И. Егоров